ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2025 елның 11 марты

№9

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм күмү эше турында» 2025 елның 13 гыйнварындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җирләү һәм күмү эше турында»1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Үлгәннәрне күмү буенча гражданнарның хокуклары гарантияләре турында»1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм күмү эше турында» 2025 елның 13 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карар преамбуласында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары белән «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 13 гыйнварындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм күмү эше турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм күмү эше турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 пунктта «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары белән», сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2, 8.4, 9.4 пунктларда «5,0 кв.м (2,0 м х 2,5 м) тәшкил итә (2,2 м тирәнлек)» сүзләрен «2,0 м х 1,0 м х 2,2 м тәшкил итә (озынлыгы, киңлеге, тирәнлеге)» сүзләренә алмаштырырга.»;

7.3 пунктта «5,0 кв. м (2,0 м х 2,5 м) тәшкил итә (2,2 м тирәнлек)» сүзләрен «2,0 м х 2,5 м х 2,2 м тәшкил итә (озынлыгы, киңлеге, тирәнлеге)» сүзләренә алмаштырырга.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17 йорт административ бина, Киров ур., 23 йорт, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, Ленин урамы, 32 йорт, Шөгер авылы мәдәният йорты, Ленин урамы, 35 йорт, Шөгер участок хастаханәсе, Горький урамы, 4 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Н.Гафиятуллин